Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшләк авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 13**

Зур Мәшләк авылы 2017 елның 22 августы

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Советының 2014 елның 8 октябрендәге “Җир салымы турында” 11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 5 маддәсенең 4 өлеше, 31 бүлеге (икенче өлеш), «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 декабрендәге 396-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 маддәсендәге 10 өлешенең 3 пункты, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Советының 2014 елның 13октябрендәге “Җир салымы турында” 9 номерлы” карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Советының 16.11.2014 ел, № 10, 28.05.2015ел, №11) карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән ) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктны түбәндәгечә үзгәртергә:

«5. Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә салым базасын киметү хокукын раслаучы документлар салым түләүчеләр тарафыннан үз теләге белән салым органына тапшырыла».

Карарны Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Зур Мәшләк авылы, Школьная урамы, 13А йорт; Югары Мәшләк авылы, Нариманова урамы, 24а йорт; Бикчурай авылы,М.Горький урамы,50А йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2016 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшләк авыл җирлеге Башлыгы Фатихов А.М.